Sabira Stahlberg

# Miranda



**Sabira Stahlberg**

# Miranda

**Fazile Nasretdin tärcemäse**
**Maria Viitasalo räsemnäre**

Helsinki 2022

*Tampere tatar cämiyätenä (Tampereen tataariseurakunta, per. 1943), Finlandiya İslam Cemaatinä (Suomen Islam-seurakunta, per. 1925) häm Oskar Öflund vakıfına matdi yärdämnäre öçen samimi rahmätlärebez.*

OSKAR ÖFLUNDS STIFTELSE

**Ciñel tel däräcäläre**
**Däräcä 1: İñ ciñel**
Däräcä 2: Ciñelräk
Däräcä 3: Ciñel

Tatar, 2. basma / edition
Şved telendä / Original: *Miranda*
Tärcemä: Fazile Nasretdin
Eş törkeme: Albina Samarhan,
Kamer Yafay Nogmanov, Derya Samaletdin,
Adile Samaletdin, Nergis Samaletdin, Liliä Däülät

© Sabira Stahlberg 2022
© Fazile Nasretdin, tärcemä / translation 2022
© Maria Viitasalo, räsemnär / illustrations 2022

Bokpil ▸ bokpil.eu
Aybagar ▸ aybagar.eu
Helsinki 2022

ISBN 978-952-7334-32-4 (Kägaz kitap)
ISBN 978-952-7334-33-1 (E-kitap, PDF)

# Bülem 1

Minem isemem Sara Miranda.
Saranı yaratam,
läkin Miranda bik säyer isem.

Äniyem äytä:
‒ Miranda isem äybät.
Äbiyemneñ iseme.
Äbi yahşı keşe ide.
Ul batır da, akıllı da ide.

Mäktäptä hämmäse miña, Mira diyä.
Äti-äni dä miña, Mira, diyä.
Mira kıskarak häm
äytergä dä ciñelräk.
Bu ätineñ fikere.
Miña Mira yahşırak kileşä imeş.
Buyım da kıska bit.

Sara, dip edäşsälär ide.
Läkin berkem dä döres
isememne kullanırga telämi.

Berni tügel.
Barıber mäktäptä dä, öydä dä
berkem minem belän söyläşmi.

Min äti-äni belän yäşim.
Tugannarım yuk.
Fatirıbız küpkatlı yortnıñ öçençe katında.
Yortıbız ak töstä, balkonnarı sarı.
Sarı tösne yaratam,
aknı yaratmıym.
Miña kalsa, ak salkın tös.

Äni dä, äti dä öydä siräk bulalar.
Minem belän söyläşergä
vakıtları yuk.
Haman eştälär.
Kibetebez bar.
Ul irtädän kiçkä açık.

Kayvakıt kibetebezgä baram.
Äni yäki äti belän beraz
söyläşergä telim.
Alar söyläşergä ölgermilär.
Kibet haman halık belän tulgan.

Kibetne yaratalar.
Anda aluçılar äyber
alırga kerälär.
Söyläşer öçen genä dä kerälär.

– Akıllım, kiç belän söyläşerbez, äni äytä.
Amma kiçen söyläşergä köçe yuk.

Öygä kaytkanda ikese dä
äni dä, äti dä ütä arıgannar.
Küp vakıt min yalgız.
Mäktäptä dä min yalgız.
Miña berkemneñ dä ise kitmi.

Yuk, çınnan da alay tügel.
Min alarnı kızıksındıram kebek,
läkin orışır öçen genä.

Tukta.
Ägär kemder kızıksındıra ikän,
anıñ belän orışıp toralarmı?
Işanmıym.

Ägär kemder çınnan da
kızıksındıra ikän,
ul keşe belän orışmıylar.
Ägär beräü belän kızıksınabız ikän,
ul keşene bez yaratabız.
Min şulay uylıym.

Mine mäktäptä yaratmıylar.
Malaylar kitaplarımnı
alalar da kaçıralar.
Kızlar çäçemnän tartalar.
Alarga şulay küñelle.
– Kızıklıybız gına, dip äytälär.

Härkön başmaklarımnı da
ezlärgä turı kilä.
Mäktäptä hiç tä küñelle tügel.

Açık itep fikeremne äytimme?
Mäktäpkä barırga min kurkam.
Bik yış kitaplarımnı,
kalämnäremne yäki
biştäremne tapmıym.
Mäktäptän öygä kaytırga da kurkam.
Äni ni äyter?

‒ Nigä äyberläreñne haman
yugaltasıñ, sorap tora.

Yoklıy da almıym.
Başım härkön diyärlek avırta.
İrtä torırga telämim.
Çınnan da,
mäktäpkä barırga telämim.

Bolay itenügä bäylänü
dip äytelä, uylıym.

# Bülem 2

Kitaplarım küp. Min küp ukıym.
– Artıgı belän ukıysıñ, äni äytä.
Uyınçık ayuım bar.
Anıñ iseme Yöntäs.
Ul minem berdänber dustım,
berkayçan da orışmıy,
ber süz dä äytmi.

Yöntäs mine mäktäp
kaygılarımnan saklıy almıy.
Anı anda alıp barırga da kurkam,
çönki min anı saklıy almıym.
Başkalar aña usallık eşlärlär dip kurkam.

Bügen mäktäptä adättän tış kön.
Böten mäktäp autubus belän
delfinariumga bara.
Autubusta ukıtuçıbız delfinnar turında añlata:
– Delfinarium bik zur bina.
Anıñ eçendä havız bar.
Havız su belän tutırılgan.
Anda delfinnar yäşi.

Beräü autubusta sorıy:
– Delfinnar niçek suda yäşi alalar?

Alar bit imezüçe hayvannar.
Ukıtuçı apa añlata:
– İmezüçe hayvannarnıñ
ber öleşe suda yäşi ala.
Çınbarlıkta delfinnar diñgezdä yäşilär.
Läkin delfinariumda yäşi torgannarı da bar.
Alar keşe yaratalar.
Delfinnar bezgä fokuslar eşläp kürsätälär.
Törle fokuslar çıgarırga yaratalar.

Bu eşkä bik ışanmıym.
Minemçä, delfinnar fokuslar kürsätälär,
çönki alarnı ul eşkä mäcbürlilär.
Çınbarlıkta alar kayber keşelärne
hiç tä yaratmıylar.
Keşe alarnı totkın itkän bit.

Delfinariumga keräbez.
Üzemä ber şäp urın tabam.
Çat havız yanındagı eskämiyägä utıram.
Başkalar mömkin kadär artka baralar.
Minem belän utırırga telämilär.
Minem aldımda berkem dä utırmıy.

Havıznı böten küläme belän küräm.
Hattä delfinnarga totına alam diyärlek.
Delfinnar havıznıñ ber çitenä yözep kilälär.
Alar miña bagalar da kanatların kagalar.

Üzläre zur, küzläre söykemle.
Delfinnıñ başınıñ
tübäsendä ber tişek bar.
Tişek ütäli ul tın ala.
Suga çumganda tişek yabıla.
Havaga mengändä açıla da,
çıkılt itkän tavış işetelä.

Minemçä delfinnar bik matur.
Alarnıñ arka yagı sorı,
korsakları ak töstä. Küzläre kara.
Delfinnar tiz yözälär.
Zur bocralar ütä sikerälär.
Ber-berlären havızda kualar.
Oy, alar şundıy söykemle!



# Bülem 3

Äle delfinnar bi´i.
Delfinnarnıñ biyegännären kürgäneñ barmı?
Ul bik matur küreneş.
Alar cırlaşalar häm sızgırışalar.
Tavışları şıgır-şıgır kilä.

Delfinnar bertuktamıy kölälär kebek.
Närsädän kölälär ikän,
anısın belmim.
Alarnı tıñlaganda
üzemne şat toyam.

Ber ir keşe havıznıñ ber çitendä baskan.
Kulında çiläk, çiläktä balıklar.
Delfinnarga balık bärep tora.

Kinät ber delfin sudan sikerep çıga da,
irne törtep ala.
Ul havızga töşep kitä.
Çiläk tä şunda suga bata.
Delfinnar kölälär.

Tiz genä balıklarnı yotıp kuyalar.
Min şarkıldap köläm dä,
urındıgımnan töşep kitäm.

Tezemne idängä sugam.
Avırttırdım, läkin avırtuın
tiz onıtam.
Äle delfinnar tup belän uynıylar.
‒ Saklanıgız! dip ukıtuçı apabız kıçkıra.

Delfinnar tupnı baguçılarga bärälär.
Annarı barısı da bervakıtta
suga çumıp alalar.
Östemä su çäçrätälär,
läkin min borçılmıym.

Alkışlıybız.
Bik katı kul çabam da,
kullarım kızara.
Delfinnar rahmät ukıylar.
Baguçılarga baş iyälär.

Annarı tagın da balık telilär.
İr havızdan çıga da,
ikençe çiläk balık alıp kilä.

Delfinnar balık aşarga yaratalar.
Min dä balık aşarga yaratam.
Min belgän balıklardan
iñ yaratkanım kızdırgan salakuş.

# Bülem 4

Delfinariumnan tup-turı
öygä kaytam.
İşek töbendä tuktıym.
Kesämdä kazınam.
Anda telefon häm dä narat tubırçıgı.

Açkıçlarım kayda?
Kesäne töbenä kadär kazınam.
Biştäremnän ezlim.
Açkıçlarım berkayda da yuk.

Panikaga birelgänemne sizäm.
Başta eçem ju itep kitä,
annarı tamagıma töyer utıra.
Açkıçlarımnı yugaltkanmın.
Äle tuktap uylarga kiräk.
Alarnı soñgı märtäbä kayda kürgän idem?

Açkıçlar mäktäptä häm dä
delfinariumda kesämdä ide.
Läkin äle yuk.
Kayda yugalttım ikän?
Yılıysım kilä.
Öygä kerä almıym.
Änineme kötärgä kiräk?

Yäki ätigä şaltıratırgamı ikän?
Bügen äti änidän elegräk kayta.

Äni kiç belän soñ kayta.
Ul arıgan, açulı häm açıkkan bula.
Kön buyı kibettä basıp tora.
– Çıdıy almaslık kön ide!
dip başın totıp haman kabatlıy.

Yuk, änigä şaltıratmıym.
Ul barıber yärdäm itä almıy.
Miña üzemä buldırırga kiräk.
Açkıçlarnı yugalttım, üz hatam.
Nişlärgä ikän, dip uylanıp toram.

Äle beldem kayda yugalttım,
alay da şulay uylıym.
Delfinariumda köldem dä,
urındıgımnan töşep kittem.
Şunda açkıçlarım
kesämnän töşkänder.

Miña yabılgıynçaga kadär
delfinariumga ölgerergä kiräk.
Kemder açkıçlarnı tapkandır.
Açkıçlarımnı miña, älbättä, tapşırırlar.
Vakıtında ölgerergä kiräk.



# Bülem 5

Delfinariumga autubus belän kire kaytam.
Min bik nervalı.
Uylap karaçı, hämmäse
annan kitkän bulsa inde?
Uylap karaçı, berkem dä
açkıçlarımnı tapmagan bulsa?

Eçem ju itä.
Kullarım kaltırıy.
Ayaklarım peşkän spagetti kebek yomşak.

Uylap karaçı, beräü miña açulansa?
Mine eçkä kertmäsälär?
Bälki yapkannar da inde.
Uylap karaçı, açkıçlarımnı tapmasam?

Autubustan töşep kalam.
İşek aldında tuktıym.
Delfinarium yabık.
Bina tıp-tın häm karañgı.

İşektäge kägaz kisägendä
sägat sigezdän unaltıga açık dip yazılgan.
Atnaras häm bazarkönnärne
delfinarium yabık.

Çınnan da bolay bula almıy.
Eşem uñmadı.

Bügen comakön.
Dimäk, başkönnän äüväl
açkıçlarımnı ala almıym.
Bik küñelsezlänäm dä,
kitärgä äylänäm.
Şunda uyıma ber närsä kilä.

İşek yanına kaytam.
İşek ütä kürenmäle pıyaladan.
Binanıñ eçenä kürä alam.
Anda divarda zur sägat bar.
Sägatkä karıym.
Sägat dürtne unbiş uzgan.

Artık soñ, läkin
kemder eçtä yörenä.
Äy, delfinnar gına
havızda sikerenep tora.

Yılıy başlıym.
Äni ni äyter? Äle ni eşlim?
Ni dä eşli alamınmı soñ?

# Bülem 6

Çat şul vakıtta ber ir keşe
işek yanınnan uza.
Çalbarı kara, külmäge zäñgär.
Üze ozın häm yabık, çäçe kara.

Min anı hazer ük tanıym.
Ul tege delfinnarnı aşatkan ir.
Suga töşep kitkän abıy!
Därtlänep işekkä kagam.
Mine işetäme? Tuktarmı?
Yuk… üz yulın bara.
– Tukta, kıçkırıp kuyam da,
katırak kagam.

Äye! Nihayät.
Mine işetä dä äylänä.
Miña, köt, dip kulı belän kürsätä.
Abıy açkıç alıp kilä dä,
işekneñ bigen aça.

– Hey, sin monda nişliseñ,
dip sorıy. – Yaptık inde.
– Afu itegez. Beläm, yabık inde.
Läkin min açkıçlarımnı yugalttım,
oyalıp äytäm.

– Monda, delfinnar yanında.
– Ähä, genä äytep cavap kaytara.
Min oyatımnan cir tişegenä kerer idem.
Yäisä yırakka kaçıp kitär idem.
Abıy başın kaşıp ala.
Annarı başın kıñgır salıp:

– Ähä, tagın ber tapkır äytä.
– Turısın äytkändä, miña berkemne dä
eçkä cibärergä yaramıy.
Alay bulsa da kil, ker!

– Min sezne avır halgä kaldırırga
telämim, äytäm.
– Açkıçlarımnı gına barıp alam.
Ber minuttan kübräk ütmi.

– Açkıçlarnı yugaltu ul zur
krizis dip sanala.
Krizis öçen sine eçkä cibärä alam.
Açkıçlarıñnı tababız inde.
İsemeñ niçek? dip sorıy.
– Mira, dip äytäm.
– Afu, döres tügel.
İkençe isemem dä bar.
Döres isemem Sara. Sara Miranda.

Abıy kölä.

– Beläseñme närsä?
Sin minem señelemä ohşıysıñ.
Ul baytak üzençälekle kız.
Bälki şul uk mäktäpkä yöriseñ, dip äytä.
– Işanmıym, mıgırdanam.

Abıy dävam itä:
– Min Miranda isemle
beräüne tanıym.
Anıñ belän küreşergä teliseñme?
Ul iskitkeç.
Miranda isemneñ magnäse dä iskitkeç.
Anı beldeñme?

– Alaysa min dä iskitkeçter,
uylamıyça gına äytep kuyam.
Abıy tagın kölep cibärä.
Yahşı keşegä ohşıy.

– Älbättä, abıy äytä.
– Böten Miranda isemle kızlar
äybät bulırga tiyeş.

Esse bulıp kitte.
Nigä? Yahşı gına añlamıym.
– Äydä, minem belän kil, abıy çakıra.

# Bülem 7

Havız yanına barıp citäbez.
Abıy üze turında añlata.
İseme Markus.
Ul universitetta biologiyä ukıgan.

Öç yıldan birle delfinariumda eşli kilä.
Eşen bik yarata.
Mäktäbem turında soraşa.
Señele başka mäktäpkä yöri dip añlaşıla.
Minem belän ber yäştä ikän.
Markus, dönyada barlık
närsälärdän iñ küp
delfinnarnı yarata ikän.
Min dä alarnı yaratam, dip äytäm.

‒ Delfinnar siña cırlıylar.
İşetäseñme? Markus añlata.
‒ Bu mahsus cırnı siña gına çıgaralar.
Sin kem? dip sorıylar.
Huş kildeñ, dip sälamlilär.
Min dikkat belän tıñlıym.
Äye, delfinnar çınlap ta miña cırlıylar!
Alar havızda mine yözep uzalar.
Küzläre häm haräkätläre belän
miña söylilär dip belgertälär.

Tavışları kızık yañgırıy.
Şıgırdıy da sızgıra.
Keçkenä balalarnıkı kebek.

– Alar keşelär kebek küp söylilär,
acäplänep äytäm.
– Alar äldä kübräk söylilär,
Markus cavap birä.
– Alar tuktausız söylilär.
Barı tik yämle häm yahşı
eşlär turında gına söylilär.
Mäsälän balıklar turında!

– Ni äytälär? sorıym.
– Äle hazer aşarga telilär.
Bolay, min dä telim.
Dönyada iñ yahşı närsä aşau.
Sin ikmäk belän päynir yaratasıñmı?
Yäki teläbräk kazı belänme?
Markus sorıy.

– Älbättä, cavap biräm.
– Bik yaratam.
Päynir yaratam dip äytergä telim.

Annarı uñaysızlanam.
Miña ni bulsa takdim itelsä,
äni yuk rahmät äytergä öyrätte.

Kem bulsa kunakka çakırganda gına
rahmät äytälär.
Bälki äle min kunak?
Markus urındıkka utıra.
Çantadan ber keçkenä paket çıgara.
Miña päynirle ikmäk suzıp birä:
‒ Rahim it.
Sin bik açıkkansıñ inde, dip äytä.

Äye dip baş kagıp belgertäm.
Çınnan da açıkkanmın,
elegräk sizmädem genä.
Artık nervalangan öçen
aç bulganımnı sizmädem.

‒ Äle añladım, Markus äytä.
‒ Sin bügen biredä mäktäp belän ideñ.
Haterlim. İñ alda utırgan ideñ.

Markusnıñ ikmäge östendä kazı.
Kazıdan ber kisäk alıp kaba.
Min päyniren tämläp karıym.
‒ Sin yahşı keşe.
İkmäk tä tämle, äytäm.

Markus ikmägen çäyni.
‒ Rahmät. İkmäklärne üzem äzerlim,
dip äytä.

Annarı beraz vakıt uylana da,
dävam itä:
– Min äldä yahşı keşe tügel.
Bälki dä yahşı bulırmın.
Berkönne.
Kem beler?
Delfinnar, alar çınnan da akıllılar.
Alar ber-berlärenä yärdäm itälär.
Keşelärgä dä yärdäm itälär.



# Bülem 8

– Delfinnar bezgä niçek yärdäm itälär?
isem kitep sorıym.
– Alar sineñ käyefeñ niçek ikänen belälär.
Sin şatmı, kaygılımı, anı da belälär.
Sin şat bulsañ, alar da şat.
Sin kaygılı bulsañ,
alar sine kölderälär, Markus añlata.

– Delfin kürsäm, şatmı bulam? sorıym.
– Älbättä, Markus añlata.
– Alar yış-yış kölälär.
Alar belän sin kölmiçä tora almıysıñ.
Alarnıñ kölüläre yabışa.

– Şunıñ öçenme sin haman
kölep torasıñ? sorıym.
Markus şundıy katı kölä,
havıznıñ här yagı yañgırıy.
Annarı citdilänä dä sorıy:
– Sin berkayçan da kölmiseñme?

Min başımnı çaykatam da, idängä bagam.
– Sin nigä kölmiseñ?
Berkayçan damı şat tügelseñ?
Markus sorıy.

– Minem bernärsädän dä kölärlegem yuk,
dip cavap biräm.

– Bu süzeñä ışanmıym, Markus äytä.
– Härkem kölä ala.
Härkemgä kölärgä kiräk ide.
Kölü faydalı.

Havızga karap toram da, añlatam:
– Mäktäptä äyberläremne kaçıralar.
Miña yämsez kıçkıralar.
Minem turımda usal süzlär yöretälär.
Alar, min ahmak häm yämsez, dip söylilär.

Markus uylana da äytä:
– Min kemnän dä kölmim.
Min şat bulganda gına köläm.
Tämle ikmäk aşaganda da köläm.
– Ul citäme? min sorıym.

– Bügen kük yöze zäñgär
bulganga da min şat, Markus dävam itä.
– Häm dä koyaş balkuı öçen min şat.
Delfinnar şat bulganga,
iñ küp köläm.
– Min bälki berkayçan dörestän dä
şat bula almıym, dip äytäm.

# Bülem 9

Markus yılmaya da, barmagı belän
havızga kürsätä:
– Delfinnar arada kurkalar,
arada kaygılılar da.
Läkin haman tagın şat bulalar,
dip añlata.

Başımnı selketäm.
Min anıñ äytkännärenä ışanmıym.
Markus dävam itä:
– Alar sine üzeñ bulgança yaratalar.
Alar berkayçan da sin ahmak
yäki yämsez dip äytmilär.
Alar sine nibarıñ belän kabul itälär,
dip añlata.

Min anarga tagın da ışanmıym.
– Şat bulırga bik ciñel tügel, äytäm.

– Döres äytäseñ.
Bezgä keşelärgä ul avırrak.
Bez bik törle eşlär uylap yatabız.
Delfinnar üzgäçä.
Alar uynarga da
cırlarga da yaratalar.

Korsakların sıypasañ,
inde bik tä yaratalar,
Markus yılmaya.
‒ Annarı şatlanalarmı? acäplänäm.
‒ Älbättä! Kil, üzeñ kürerseñ,
Markus äytä.

Markus kulın suga tıga da,
sunı çäçrätä başlıy:
‒ Hey, Miranda, kıçkırıp cibärä.
Tirä-yak tın.
Tagın sunı çäçrätä,
ämma ber delfin dä kürenmi.

‒ Miranda balık teli torgandır,
Markus tavışka uylana.
‒ Delfinnarnı aşattım bit inde.
Dimäk, anarga ber balık kına elägä.
Artık küp aşasa,
hale yahşı bulmıy,
dip söylänä.

Markus balık alırga kitä.
Min su astına karıym.
Havız şul kadär tirän,
töben kürä almıym.
Annarı Miranda kilä.
Sudan sikerep çıga.

Äzme miña timi.
Annarı suga kire çuma.

– Yugaldı, dip kıçkıram.
– Miranda tizdän tagın kiler,
Markus kölä.
– Anı aşatırga teliseñme? sorıy.
Miña ber balık birä.
Balık taygıç häm dä salkın.
Balıknı äkren genä su
östendä totıp toram.

Miranda havıznı yözep äylänä.
Annarı borının kütärä.
Balıknı kürä.
Kulım turında tuktıy.
– Nindi matur,
dip pışıldap äytäm.



# Bülem 10

Miranda başka delfinnarga
karaganda keçkenäräk.
Anıñ avızı ozın häm
ütken teşläre küp.
Tele alsu tösle.

Miranda kebek yämle hayvan
bälki dä berkayçan da
kürgänem yuk.
Häm dä ul miña yılmaya!

Miranda suda äkren genä tora.
– Ul kötä, Markus pışıldap äytä.
– Ul sine tikşerä, sin nindi keşe ikän.
Kurkınıç tügel dip
ul üz-üzen ışandıra.
– Min kurkınıç tügel bit,
karşı kuyam.
– Berkayçan da belep bulmıy,
Markus kölä.

Annarı Miranda yakınrak kilä.
Kanatların kaga.
Balıknı kulımnan ala da,
su astına yugala.

– Delfinnı äle sıypıy alasıñ,
Markus äytä.
– Ul sine yarata.
Annarı Markus ike kulı belän dä
havız çiten şakıldata.
Miranda sudan yözep çıga da,
bik yakınga kilä.
Korsagın öskä taban äyländerä.
– Rahim it, Markus äytä.

Min Mirandanıñ korsagın
saklanıp kına sıypıym.
Tirese katıga toyıla.
– Bötenläy yüeş bit, kıçkırıp cibäräm.

Markus şundıy katı kölä,
havızga töşä diyärlek.
– Älbättä ul yüeş.
Ul bit suda yäşi, dip añlata.

Delfin dä kölä.
Alar şulay katı kölgängä,
mine dä kölderä başlıy.
Eçem katıp köläm dä,
eç muskullarım
avırta başlıy.

Alay bulsa da kölärgä kızık!

# Bülem 11

Başka delfinnar Miranda
yanına cıyılalar.
Alar bişäü.
Havızda alar kübäü.

– Duslarıbız balık telilär, Markus äytä.
– Ägär bersenä rizık birsäñ,
barısın da aşatırga kiräk.
– Markus, Mirandaga usallık eşlämilärder?
borçılıp sorıym.
– Yuk. Delfinnar ber-berlärenä
usallık eşlämilär.
Alar yakın duslar,
Markus cavap birä.

– Nigä soñ ber-berlären törteşkändä
kurıkınıçka ohşıy, sorıym.
– Alar ara-sıra uynıylar da, şunda
ber-berlären törtenälär.
Şulay ber-berlären yaratalar
dip añlatalar, Markus açıklıy.

– Ägär dä kemne bulsa yaratsañ,
anı borçıp torırgamı tiyeş?
soraşa başlıym.

– Diñgezdä delfinnar kayçan bulsa
ber-berläre belän orışalar
yäki sugışalarmı?
– Bik siräk.
Delfinnar törkemnärdä yäşilär.
Alarga bergä torırga kiräk,
çönki alarnıñ doşmannarı küp.
Akula törkemnärenä höcüm itsä,
barısı da aña karşı çıga, dip
Markus cavap birä.

Min mäktäpne uylıym.
Barısı da miña karşı.
Nigä? Añlamıym.

Min bit akula tügel.
Hiç kurkınıç ta tügel.
Nigä miña höçüm itälär?
Markustan sorarga karar kılam.

– Markus, nigä keşelär
ber-berlärenä usal? kurkıp sorıym.

Markus başın kaşıy da äytä:
– Belmim şul, läkin kaysı beräülär
hokem itärgä telilär.
Üzläre dönyanıñ iñ zur häm iñ köçle
keşeläre bulırga telilär.

– Ul ahmaklık.
Tämam idiotlık, äytäm.
– Min dä şulay uylıym.
Läkin faydası yuk.
Andıy keşelär barıber küp,
Markus cavap birä.

– Çitlätelgän keşe bik
yış azap kürä bit, mıgırdanam.
– Bäylänüçelär nindi küp zarar
kitergännären añlamıylar,
Markus äytä.

– Añlasalar, tuktarlarmı ide?
Yäki dä alarga başkaları
bäylänsä? sorıym.

– Törleçä buladır,
Markus cavap birä.

Miranda bornın sudan çıgara.
– Balık kübräk telim,
dip sabırsızlıgın belgertä.

– Äye, äye, balık kübräk elägä,
Markus kölä.
– Läkin irtägä genä!

# Bülem 12

– Markus, sin ni äytäseñ? sorıym.
– Nigä orışudan tuktarlar ide?
Ul bit alarga kızık.
Orışudan täm tabalar dip äytälär.

– Barısı da çınnan da ber fikerdä tügel,
Markus iskärtä.
– Aralarında ber citäkçeläre bula.
Başkaları çittä tora.
Bäylänälär, läkin başlık bulmıylar.
– Ul sanalmıymı soñ? sorıym.
– Alar da bäylänälär. Älbättä.
Läkin başlıkları bulmaganda
alar tuktıylar, Markus añlata.

– Nigä soñ alar katnaşalar? tavışka uylanam.
– Alarnı da mıskıllarlar dip kurıkalar.
Anıñ öçen berni dä äytmilärder,
Markus uylana.

– Min beläm, äytäm.
– Beräüläre sıynıfımda iñ naçarlar.
Başkalar alarga iyärälär.
Kaysıları bulsa tik kenä tora.
Beraz vakıt üz-üzemä uylanam.

Kızık. Äyterseñ Markus barısın da belä.
Ul belgän keşeläremnän mine iñ yahşı añlıy.

– Sin niçek bäylänü turında
şundıy küp beläseñ? sorıym.
– Ütkän yılnı kız tuganımnı
mıskıl ittelär, Markus citdi genä añlata.
– Niçek buldı soñ? sorıym.
– Tuganım eşne tuktattı, Markus añlata.

– Alay bula ala dip ışanmıym.
Mıskıllauçılarnı tuktatıp bulmıy, dip äytäm.
– Älbättä bula, Markus äytä.
– Tuganım açulandı da, anı açık
itep belgertte. Ailäbez yärdäm itte.

Min şiklänep toram.
Çın bulganına ışana almıym.
– Yärdäm itteme soñ? dip acäplänäm.
– Başta yärdäm itmäde.
Mäktäptä bäylänülären dävam ittelär.
Läkin tuganım birelmäde.
İke ay ütkäç inde, berkemneñ dä
aña yämsez söylärgä kıyulıgı citmäde.
– Miña kalsa berkayçan da tuktamıylar,
äytäm dä, küñelsezlänäm.
– Min üzsüzle tügel.
Min kurkak, diyäm.

# Bülem 13

Miranda borının havız çitenä kuya.
– Bez artık küp söyläşäbez
dip uylıy, Markus äytä.
– Miranda, tıñla, ni uylıysıñ?
Bezgä ni eşlärgä kiräk ide? süzen dävam itä.

Miranda söykemle küzläre belän miña karıy.
Başın äyländerä dä,
koyrıgı belän sunı çäçrätä.

– Ul siña kurkarga kiräkmi
dip äytä, Markus añlata.
– Mira, sin älbättä, küp närsälär beläseñ.
Belgännäreñne alarga kürsätsäñ
yäki añlatsañ, ni bulır soñ?

– Belmim inde, belergä telilärme, cavap biräm.
– Mäktäpkä bargaç
üzemne çitlektä kebek toyam.
– Nigä alay? Markus sorıy.

– Berni dä äytergä kurkam.
Närsä genä äytsäm dä, alar tagın da
kübräk usal süzlär miña
kıçkıra başlıylar, añlatam.

Markus başın selketä.
– Siña azat bulırga kiräk, äytä.
Berkemgä dä kem ikänlegeñä
çiklär kuyarga rohsät birmä,
dip kiñäş itä.

Miranda kanatların kagına.
Ul sızgıra da şıgırdıy.
– Delfinnarnı kara, Markus äytä.
– Bolar havızda yäşilär.
Tabiättä diñgezdä yäşilär.
Alar könenä yöz çakırımnan
artık yözä alalar.
Läkin havızda andıy ozın
yullar yözep bulmıy.

– Alay bulgaç, alarnı azatlıkka
cibärergä kiräk ide, äytäm.

– Yuk, alay bulmıy.
Bolar havızda tugan.
Miranda berkayçan da
diñgez kürgän dä yuk.
Ul tabiättä isän kala almas ide,
Markus açıklıy.

– Barlık hayvannarga azat
bulırga tiyeş bulır ide, mıgırdanam.

– Min dä şulay uylıym,
Markus äytä.
– Kırgıy delfinnarnı
totkın itärgä yaramas ide.
Läkin Miranda kebek delfinnarnıñ
urını delfinariumnarda.

– Üzen totkın dip toymıymı?
acäplänäm.
– Anısın belmim, läkin uylamıym.
Miranda diñgezdä
açka ülär ide,
anısın beläm.
Hastalanırga dä mömkin.
Bez anı biredä bagabız bit,
Markus äytä.

– Biredä akulalar yuk, äytäm.
– Döres, Miranda yätmägä
dä eläkmi.
Havıznıñ suı aru.
Anarga küp rizık birelä.
Berkem anı monda aulamıy,
Markus östep äytä.



# Bülem 14

Miranda suda äylänä, koyrıgı belän
sunı çäçrätä. Havızda tirängä çuma.
Başka delfinnar belän bergä
havıznı äylänep yözä.

– Mirandaga çik kuysalar,
yaratmavın ul açık itep kürsätä.
Bötenläy tıñlamıy, Markus añlata.
– Niçek soñ alay? acäplänäm.
– Tuktıy da kuya, Markus añlata.
– Açık itep äytä: Stop.
– Anı sin niçek beläseñ? sorıym.
– Miranda tämam äkren tora.
Anıñ üzenä kürä tavışı da bar.
Ul tavış baytak kına uñaysız.
Läkin usal bulıp işetelmi, Markus äytä.

Şunda miña üz halem kırt kilep açıklandı.
Min bit mäktäptä alar belän bergä
bulırga telämägänemne sizderä alam.
Min, tämam Miranda kebek, äkren tora alam.
Mıskıllauçılar da tıngaç, alarga
ni uylaganımnı äytä alam.

Miña bäylänüläre haksız!

# Bülem 15

– Äle öygä kaytırga vakıt,
Markus äytä.
– Bişmätemne genä alıp kiläm.
Ul arada sin açkıçlarıñnı ezlärseñ, bälki dä?

Açkıçlarım!
Bötenläy onıtkan idem.
Köndez utırgan urındık yanına baram.
Andalar. Döres uylagan idem.
Açkıçlar urındık astında.
Şatlanam, çınnan da şatlanam.

Şunda Miranda miña endäşä.
Kanatları belän su çäçrätä dä kıçkıra:
– Yanıma kil! Kil!
Min kire Miranda yanına yögeräm.
Ul şunda suga çuma.
Koyrıgı belän sunı çäçrätä. Laç ta loç!

Ütä yüeşlänäm dä,
açkıçlarım kulımnan töşep kitä.
– Yärdäm, kıçkıram,
– Açkıçlarım havızga töşte.
Markus äkren genä havız yanına kilä.
Kölä. Açuım kilä.

Miña bit açkıçlarım kiräk.
Açkıçlarım havız töbendä kalsa,
äti-äni ni äyterlär?
Açkıçlarım havız töbendä ikänen
niçek añlatırmın?
Uyla ägär dä…

– Miranda açkıçlar aşıymı?
Yäki alarnı yota alamı?
sabırsızlanıp sorıym.
– Ul balık kına aşıy.
Metall artık katı.
Häm dä ul ziräk bulganga,
nindi dä açkıçlar yotmıy,
Markus äytä.

Miranda tagın borının sudan çıgara.
– Afärin kız! Markus äytä.
– Akıllım, açkıçlarnı su astınnan
alıp kiläseñme? ütenä.

Min başımnı selketäm dä sorıym:
– Niçek sineñ söyläveñne añlıy?
– Miranda barısın da añlıy,
Markus cavap birä.
– Bez genä citärlek delfinnarnıñ
telen añlamıybız.

# Bülem 16

Miranda minem aldımda tuktıy.
Açkıçlarnı alıp kaytkan.
Alar belän uynıy.
Havaga bärä dä, tagın totıp ala.
Açkıçlarnı suga töşerä dä,
alır öçen kire çuma.
Kölmiçä tora almıym.

– Dikkatne üzenä tartır öçen
şulay itenä, Markus açıklıy.
– Ul bezneñ kebek söyli almıy.
Şunıñ öçen ul kıçkıra da çäçrätä.

– Närsä telägänen beläm, äytäm.
– Mine şatlandırırga teli.
– İskitkeç, tügelme, Markus tirän sulap äytä.
– Sin Mirandaga soklangansıñ,
kölep cibäräm.
– Älbättä, Markus yılmaya.

Sägatemä karıym. Bişne uzgan.
Äti kaytkandır.
– Miña kaytırga kiräk, äytäm.
– Açkıçlarıñnı telämiseñme?
Markus acäplänep sorıy.

– Äye, ämma… başlıym.
– Açkıçlarımnı miña
bir disäm, Miranda añlıymı?
– Miranda zihenle, Markus äytä.

Markus kulların suza. Min dä suzam.
– Miranda, açkıçlarnı alıp
kilä alasıñmı? sorıym.

Miranda çuma da, tagın sudan çıga.
Açkıçlarnı avızında tota da,
havıznıñ çitenä kiterep kuya.
Annarı sızgıra.
– Ul sineñ yañadan kilüeñne teli,
Markus tärcemä itä.
– Miranda belän tagın küreşä alamınmı?
Sineñ belän küreşerbezme tagın? sorıym.

Markus başın kaşıy da:
– Başkönne bu vakıtta kil.
Teliseñme? sorıy.
– İşeklärne yapkaç
kilüçelär dä yuk inde.

– Äye, älbättä.
Bik teläp kiläm, cavap biräm.
– Dimäk, başkönne küreşäbez,
Markus äytä.

# Bülem 17

Minem isemem Sara Miranda.
Beräülär miña Mira di.
Minemçä Sara da, Miranda da
maturırak yañgırıy.
Mirandanıñ magnäse iskitkeç.
Saranıñ magnäse prinsessa.

Äüväl üz-üzemne yaratmıy idem.
Kurkak idem.
Mäktäpkä barırga kurka idem.

Mäktäptä minem äyberläremne kaçıralar ide.
Bitemä yämsez süzlär äytälär ide.
Berkem minem dustım bulırga telämi ide.
Küp vakıtta yalgız idem.

Äle mäktäpkä barırga kıyulıgım citä.
Kayçakta.
Üz-üzem bulırga kurkmıym.
Kayçakta.
Mıskıllaunı kabul itmägänemne
açık itep äytäm.
Kayçakta.
Bälki dä berkönne
dörestän dä batır bulırmın.

Häm bälki dä berkönne
kön buyına şat bula alırmın.
Äle mäktäp tışında ike dustım bar.
Yuk, öç. İñ ışanıçlı dustım Yöntäs ayuım.
Küñelsez bulganda,
ul haman da yanımda.

Yaña dustımnıñ iseme Miranda.
Ul delfin. Minem belän uynarga yarata.
Miña ürnäk kürsätä.
Miranda mine üz-üzem bulırga öyrätä.

Havızda, mäktäptä,
törle urınnarda,
kayda gına keşe üz-üze bula ala.
Miranda mine şatlandıra.
İkençe yaña dustımnıñ iseme
Markus, ul keşe.
Ul minem hisläremne añlıy.

Markus miña uylar öçen
küp soraular kuya.
Ukırga kitaplar da birä,
Batır bulırga därt birä.
Yaña duslarım küp söyläşmilär.
Läkin alar küp kölälär.

Mäktäptä dä yaña dustım bar.

# Bülem 18

Mäktäptäge dustımnıñ iseme Mari.
Ul orış-talaşlarnı kürä almıy.
Sıynıfta başkalarga
karşı çıgarga kurka.
Başkalar kıçkırışkanda
ul tın gına kala.

Minem dustım bulganga,
başkalar anı çitlätälär.
Kayçakta anı mıskıllıylar da.
Şunda min alarga
tuktagız diyäm.
Minem dustımnı
kimsetergä hakları yuk.
Mine dä mıskıllarga
berkemneñ dä hakı yuk.

Mari mine bik batır dip tota.
Ul miña teräk bula
häm miña yärdäm itä.
Kaygılarımnı urtaklaşa.

Mäktäp betkäç,
öygä bergä kaytabız.
Ul bezneñ kürşe yortta tora.

Başkalar arttan kilälär,
läkin bez ikäü bulganga,
bäylänergä kurkalar.
Äle min bäylänü turında
kurkmıyça söylim.
Ukıtuçılarga da söylim.
Äni belän äti äle bik rähatsez.
Berni belmägännär ide.

Mäktäptä minem halem naçar ikän
digän habär alarga şok kebek suktı.
Äni här atna rektorga şaltırata,
mäktäptä böten mıskıllaularnı
tıyarga kuşa.

Äti ukıtuçılar belän yış-yış kiñäşläşä.
Alar da rähatsez.
Härkön minem halemne sorıylar.
Äüväl berkem soramıy ide.
Närsä cavap itärgä dä belmim.

Änigä häm ätigä delfinnar
turında añlatam.
Äni bik şatlana.
Ul hayvannar yarata.
– Beläseñme närsä? äni äytä.
– Min berkayçan da
delfinariumda bulganım yuk.

Bergä bara alabızmı? sorıy.
– Älbättä, min dä delfinnar
kürergä telim, äti süzne yalgıy.
Alar bik üzençälekle bulırga tiyeş.
Min bik şatlanam.
Äni belän ätine koçaklıym da:

– Sez alarnı yaratırsız.
Şik tä yuk,
anı min yahşı beläm.
Häm dä delfinnar
sezne yaratırlar.
Ämma anda atna
könnärendä barırga kiräk,
çönki atna ahırında
delfinarium yabık.

– Alay buldırırbız,
äni äytä.
– Bezgä atna buyı barıber
iñ azdan ike yal köne kiräk.
Kaysı kön sineñ öçen
delfinariumga
barırga iñ uñaylı?



**Miranda mäktäpkä barırga kurka.**

**Berkönne açkıçların yugalta.**
**Delfinariumga açkıçların**
**alırga kayta.**

**Anda Miranda isemle**
**delfin belän tanışa –**
**kötelmägän hallärgä duçar bula.**

**Kitaptagı räsemnärne**
**üzeñ buyıy alasıñ.**

1 ciñel tel

978-952-7334-32-4

ISBN 978-952-7334-32-4 (Kägaz kitap)
ISBN 978-952-7334-33-1 (E-kitap, PDF)

**aybagar.eu ∘ bokpil.eu**